ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 Олы Кайбыч № 504

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Лобашки авылына керү автомобиль юлы төзелеше объектын ызанлау проекты һәм территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидаршне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставына таянып, кешенең тормыш алып бару өчен уңай шартларга хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Лобашки авылына керү автомобиль юлы төзелеше объектын ызанлау проекты һәм территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1 Үткәрү датасы һәм вакыты – 2022 елның 27 гыйнвары, 14.00 сәг.

2.2 Үткәрү урыны – 422330, Республика Татарстан, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар ур., 7й. адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы.

2.3 Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Лобашки авылына керү автомобиль юлы төзелеше объектын ызанлау проекты һәм территорияне планлаштыру проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертү, гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен 422330, Республика Татарстан, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар ур., 7й. адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына мөрәҗәгать итәргә.

2.4 Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар кабул итү вакыты 2022 елның 25 гыйнварына кадәр.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Лобашки авылына керү автомобиль юлы төзелеше объектын ызанлау проекты һәм территорияне планлаштыру проекты экспозициясе 2021 елның 27 декабреннән 27.01.2022 елның 27 гыйнварына кадәр Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук 422330, Республика Татарстан, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар ур., 7й. адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында ачык булачак.

4. Әлеге карарны «Кайбыч таңнары»(«Кайбицкие зори») район газетасында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында һәм һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга(халыкка таратырга).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы
Башкарма комитет
Җитәкченең беренче урынбасары Э. Х. Заһидуллина